Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы

# КАРАР

1 апрель, 2024 ел № 49-п

2023 елга Питрәч муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында хисап проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

Питрәч муниципаль районы уставының 20 статьясы, Питрәч муниципаль районы Советының 2015 елның 30 гыйнварындагы 224 номерлы карары белән расланган Питрәч муниципаль районы территориясендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмә нигезендә, Питрәч муниципаль районы бюджетының 2023 елгы үтәлеше турында хисап проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен Питрәч муниципаль районы халкының хокукларын үтәү максатларында карар бирәм:

1. 2023 елга Питрәч муниципаль районы бюджетының үтәлеше турында хисап проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Үткәрү датасы һәм вакыты - 2024 елның 26 апрелендә 14.00 сәгатьтә;

2.2. Үткәрү урыны - Питрәч муниципаль районы Советының кече залы;

2.3. Питрәч ав., Совет ур., 18 й., 4 нче каб. адресы буенча фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, яшәү урыны адресы күрсәтелеп Питрәч муниципаль районы бюджетының 2023 елгы үтәлеше турында хисап проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр тапшырылырга мөмкин.

3. Башкарма комитетка:

3.1. 2024 елның 15 апреленнән дә соңга калмыйча Питрәч муниципаль районы бюджетының үтәлеше турында хисап проектын Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә);

3.2. Питрәч муниципаль районы бюджетының үтәлеше турында хисап проекты буенча әлеге карар белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда үтәлүе турында гавами тыңлаулар әзерләргә һәм уздырырга.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов